МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

Казан шәһәре

4.09.2015 | №277-ОД

**Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2014 елның 18 апрелендәге 91-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында

б о е р ы к  б и р ә м:

1.Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2014 елның 18 апрелендәге 91-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Административ регламент) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Д.Х.Сафиуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр Р.Х.Зарипов

Татарстан Республикасы
Сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының 2015 елның
4 сентябрендәге 277-ОД
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2014 елның 18 апрелендәге 91-ОД номерлы боерыгы белән расланган Җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Административ регламентның 1 бүлегендә:

1.3 пунктның 1.3.3 пунктчасында түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) дәүләт хезмәте күрсәтү турында булган белешмәләрне үз эченә ала»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы федераль закон («Парламентская газета», №63, 27.11-03.12.2009, «Российская газета», №226, 27.11.2009, Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, №48, 5711 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон (Российская газета, №168, 30.07.2010, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2008 елның 30 декабрендәге 325 номерлы боерыгы белән расланган Җылылык энергиясен тапшырганда технологик югалту нормативларын билгеләү тәртибе (алга таба – Тәртибе) («Российская газета»да 2010 елның 17 мартында бастырылган, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 23 июлендәге 324 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә), (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2007,

№30, 1056 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнарында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, №46, 2144 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

түбәндәге эчтәлекле яңа 1.5 пункт өстәргә:

«1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, мөрәҗәгать итүчеләргә консультация бирү тәрәзәсе.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 2 пункты). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 нче кушымта)»;

Административ регламентның 2 бүлегендә:

2.5 пунктта:

1 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Дәүләт хезмәте, шулай ук дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге (шул исәптән, Россия Федерациясе законнарында документларны тапшыруның ирекле формасы каралган очраклардан тыш, ТР Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә карата кушымтага ярашлы форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза), аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны тапшыру тәртибе»;

2 графада «оешма мөһере» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

2.9 пунктта:

1 графада «күрсәтү» сүзен «яки күрсәтүдән баш тарту» сүзләренә алмаштырырга;

2 графаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк»;

2.13 пунктта:

1 графага «шул исәптән электрон формада» сүзләрен өстәргә;

2.14 пунктта:

1 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга мөрәҗәгать итүчеләрнең керү һәм аларны кабул итү урынына, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү таләпләре»;

2.15 пунктта:

1 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Дәүләт хезмәтенең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең  вазыйфаи затлар белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып»;

2 графада түбәндәге эчтәлекле унынчы, унберенче, уникенче абзацлар өстәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазифаи зат белән мөрәҗәгать итүче арасында бер мәртәбә хезмәттәшлек итү күздә тотыла. Хезмәттәшлекнең дәвамлылыгы Административ регламент белән билгеләнә»;

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба - КФҮ), КФҮ ерактагы эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтелми»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан mpt@tatar.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алынырга мөмкин»;

Административ регламентның 3 бүлегендә:

бүлек атамасында «шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре» сүзләреннән соң «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында» сүзләрен өстәргә;

3.1.1 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә»;

3.3 пунктта:

«ышанычлы зат аша» сүзләреннән соң «, электрон формада» сүзләрен өстәргә

3.7 пунктта:

беренче абзацта «документларны карап тикшерүгә кабул итүдән» сүзләрен «дәүләт хезмәте күрсәтүдән» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураларның нәтиҗәсе: кисәтүләрне бетергәнче дәүләт хезмәте

күрсәтүдән баш тарту турында белдерү»;

3.8 - 3.9 пунктларда:

«күрсәтүне туктатып тору турында» сүзләрен «күрсәтүдән баш тарту турында» сүзләренә алмаштырырга;

3.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә һәм күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында дәүләт хезмәте күрсәтелми»;

түбәндәге эчтәлектә 3.16 пунктын һәм 3.16.1-3.16.2 пунктчаларын өстәргә:

«3.16. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (4 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша җибәрелә.

3.16.1. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, гаризаны теркәлгән документлары белән бергә терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.16.2. Бүлек белгече документларны карый һәм, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.10 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм мөрәҗәгать итүчегә почта яки электрон адрес буенча җавап җибәрә, бу хакта җавапның кәгазь күчермәсенә билге ясала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң өч көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә почта яки электрон адрес буенча җибәрелгән бирелгән (җибәрелгән) җавап»;

Административ регламентның 2 нче кушымтасында «Аңлатманың» сүзен «Тәртипнең» сүзенә алмаштырырга;

Административ регламентка 3 нче кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 3 нче кушымта

# ҖЫЛЫЛЫК ЧЕЛТӘРЛӘРЕ БУЕНЧА ҖЫЛЫЛЫК ЭНЕРГИЯСЕН, ҖЫЛЫЛЫК КИТЕРҮ МАТДӘСЕН ТАПШЫРГАНДА ТЕХНОЛОГИК ЮГАЛТУ НОРМАТИВЛАРЫН РАСЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТЕЛГӘНДӘ ГАМӘЛЛӘР ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ БУЕНЧА БЛОК-СХЕМА

Мөрәҗәгать итүче

Җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау турында гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 п. нигезендә документлар тапшыра

→ Гариза, документлар

Эшчәнлек башкару бүлеге белгече

Документлар кабул итүне, гариза һәм документларны теркәүне гамәлгә ашыра, гаризага теркәлеп бирелә торган документларның исемлеген

→ Кабул ителгән, теркәлгән документлар

Бүлек җитәкчесе

Җаваплы башкаручыны билгели һәм, тиешле карар кабул итү өчен, аңа гариза тапшыра

1 көн

→ Билгеләнгән җаваплы башкаручы

Бүлек белгече

Җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау турында эш формалаштыра. Документларны тикшерә

2 көн

Тикшерелгән документлар

документлар туры килсә

Бүлек белгече

Тапшырылган материалларның Тәртиптә куела торган таләпләргә туры килүенә анализ ясый. Җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау турында теркәлә торган хат, нормативларны раслау турында карар проекты әзерли

10 көн

Карарны теркәп, теркәлә торган хат проекты

Бүлек җитәкчесе

документлар туры килмәсә

Бүлек белгече


Мөрәҗәгать итүчегә кисәтүләрне бетерү кирәклеге турында хәбәр итә

Белдерү

кисәтүләр 10 көн эчендә бетерелмәгән

Бүлек белгече

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, белдерү проектын әзерли




Административ регламентның кушымталары исемлегенә «Техник хатаны төзәтү турында гариза» дигән түбәндәге эчтәлекле 4 нче кушымта өстәргә:

Татарстан Республикасы сәнәгать<br>һәм сәүдә министрлыгы<br>тарафыннан җылылык челтәрләре<br>буенча җылылык энергиясен,<br>җылылык китерү матдәсен<br>тапшырганда технологик югалту<br>нормативларын раслау буенча<br>дәүләт хезмәте күрсәтү<br>административ регламентына<br>4 нче кушымта

Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры урынбасары<br>– Татарстан Республикасы<br>сәнәгать һәм сәүдә министрына<br>______________________________<br>(инициаллар, фамилия)

Техник хата төзәтү турында
ГАРИЗА

Җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшырганда технологик югалту нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының _______________ №______ боерыгында җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.
Язылган:_____________________________________________________
Дөрес белешмәләр:______________________________________________
Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган боерыкка тиешле үзгәрешләрне кертүегез турында үтенәм.
Түбәндәге документларны терким:
1. ______________________________________________________________;
2. _______________________________________________________________;
3. _______________________________________________________________.
Техник хатаны төзәтү турында гаризаны карауга алудан баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны:
түбәндәге адреска документ җибәрү юлы белән: ____________________;
_________________________________________________________________
адресы буенча кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүне сорыйм.

Административ регламентка (белешмәлек) кушымтада:
вазыйфаи зат Низаметдинов Марсель Илһам улы реквизитларын түбәндәге эчтәлекле вазыйфаи зат реквизитлары белән алмаштырырга:

| | | |
|---|---|---|
| Миннекәев Радель Равил улы – электр энергетикасы һәм энергетика бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе | 210-05-23 | Radel.Minnikaev@tatar.ru |